РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

29.06.2026 | 659-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан 2019 елның 02 декабрендәге 1629-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрларын алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 29 маендагы 185-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрларын алып бару тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 02 декабрендәге 1629-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрларын алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Саба муниципаль районында муниципаль маршрутлар реестрына кертелә торган язмаларда «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясында каралган белешмәләр булырга тиеш;

**1.2.** 2.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру рәвеше аларны электрон исәпләү машиналары һәм текст файлларын һәм электрон таблицаларны төзү, карау һәм төзәтү өчен билгеләнгән белешмәләр базалары өчен программалардан файдаланып сайлап алу һәм сортларга аеру мөмкинлеген күздә тотарга тиеш.».

**2.** Рәсми рәвештә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитет
Җитәкчесе М.Р.Кәримов